ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.10.2020 г. Заинск № 484

**«Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» премиясе турында» 2018 елның 30 маендагы 896 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

«Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» премиясе турында» 2018 елның 30 маендагы 896 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (2019 елның 02 июлендәге 344 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертергә, кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында: http://zainsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **М.И.Захарова**

юрист

Е.А. Скрябина
7-07-66

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 30.10
484 номерлы карарына
кушымта

«Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» премиясе турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» премиясе (алга таба - премия) җәмәгать тәртибен саклауны гамәлгә ашыруда катнашучы Зәй муниципаль районы оешмаларының халык дружиналары әгъзаларын бүләкләү максатларында бирелә.
2. Премия квартал нәтиҗәләре буенча елына 4 мәртәбә бирелә.
Премия һәр квартал өчен тугыз премия күләмендә бирелә, шул исәптән:
- 5,0 мең сум күләмендә өч премия;
- 2,5 мең сум күләмендә өч премия;
- 1,5 мең сум күләмендә өч премия.
3. Премия бирү өчен кандидатлар булып Татарстан Республикасында халык дружиналары һәм хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләр реестрына кертелгән халык дружиналары әгъзалары тора.
4. Премия бирү өчен комиссия төзелә, аның составы Башкарма комитет карары белән раслана (алга таба - комиссия).
5. Зәй муниципаль районы оешмасының халык дружинасы штабы җитәкчесе тарафыннан кул куелган премияне бирү өчен кандидатка тәкъдимнамә әлеге нигезләмәгә кушымта нигезендә квартал тәмамланганчы 10 көн кала комиссиягә җибәрелә.
6. Комиссия үз утырышында кандидатларга тәкъдимнамәләрне карый һәм премия бирү турында карар кабул итә.
7. Комиссия үз утырышларына хокук саклау органнары вәкилләрен, дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләрен һәм халык дружиналары штаблары җитәкчеләрен чакырырга хокуклы.
8. Премия бирү турында карар ачык тавыш бирү юлы белән комиссия утырышында катнашучы әгзаларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.
9. Карар кабул иткәндә түбәндәге критерийлар исәпкә алына;
1) массакүләм чаралар уздырганда халык дружинасы әгъзасының катнашуы;
2) дежурлыкка чыгуның даимилеге;
3) административ хокук бозуларны ачыклау һәм кисәтү, хокук саклау органнарына җинаятьләрне ачуда ярдәм итү.
10. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул утырыш уздырылган көннән соң өч көн эчендә комиссиянең тавыш бирүдә катнашкан рәисе һәм барлык әгъзалары, шулай ук комиссия секретаре тарафыннан имзалана.

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен" премиясе турында нигезләмәгә кушымта

Зәй муниципаль районы территориясендә “Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен” премиясен бирүгә
тәкъдимнамә

Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме ________________________________
______________________________________________________________________

Туган елы, көне, ае ____________________________________________________

Яшәү урыны адресы ___________________________________________________

Халык дружинасы отрядының исеме һәм эшләү урыны ___________________________
______________________________________________________________________

Кандидатны Татарстан Республикасында хокук саклау юнәлешендәге халык дружиналары һәм иҗтимагый берләшмәләре реестрына кертү датасы
(елы, көне, ае) ___ _____________________________________________________

Эш урыны,
вазыйфасы _________________________________________________________
______________________________________________________________________

**Премия бирүгә тәкъдим ителүчегә хисап чорында анык хезмәтләре күрсәтелгән характеристика:**

Халык дружинасы әгъзасының массакүләм чаралар үткәргәндә катнашуы:_______________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
__________

Дежурлыкка чыгу даимилеге _____________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Административ хокук бозуларны ачыклау һәм булдырмый калу:__________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______

Хокук саклау органнарына җинаятьләрне ачуда ярдәм итү:___________________________________________________________
______________________________________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

Башка казанышлар:______________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

Халык дружинасы отряды командиры ____________________ ______________________________

(имза) (Ф.И.А.)

М.У.

«_____» ________________ 20___ ел